**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

IV чакырылыш чираттан тыш утырыш
**КАРАРЫ**

2023 елның 08 декабре № 61 Урыссу ш.т.п.

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе турында Нигезләмәне раслау хакында" 25.04.2014 № 22 карарының үз көчен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссияләр турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссияләр турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 24.09.2012 № 798 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе турында Нигезләмәне раслау хакында» 25.04.2014 № 22 Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы рәисе А.Ә. Шәфигуллин